# Себер җыры

Рамил Чурагулов сүзләре — Фәнир Галимов көе




1
"Өстемдәге ак күлмәгем
Кәфен булыр мөгаен..."
Бабам шулай җырлап киткән,
Кайталмаган башкае.

2
Рәсеме юк әткәйнең,
Булганы да югалган.
"Коп булмасын балам", диеп
Әткәй башкаен салган.

3
Ком чүлләрдә, Себерләрдә,
Җаннар асрап йөрибез.
Хет үзебез кайталмасак та,
Кайтсын моңлы җырыбыз.

4
Өстемдәге ак күлмәгем
Кәфен булмасын иде.
Туган җирем, газиз җирем,
Сагынып, өзелеп көт мине.